ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**26.05.2023**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1588**

Зеленодольск шәһәрендә Карл Маркс урамында транспорт чаралары хәрәкәтен чикләү турында

Зеленодольск шәһәрендә Карл Маркс - Заикин урамында сууткәргечне капиталь ремонтлау буенча эшләр үткәрү кысаларында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2023 елның 26 нчы маеннан 7.00 сәгатьтән 28нче маеның 19.00 сәгатенә кадәр Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлының чираттагы участогында, Зеленодольск шәһәренең Карл Маркс - Заикин урамында сууткәргечне капиталь ремонтлау буенча эшләр үткәрү чорында, транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктатуны гамәлгә ашырырга:

- Карл Маркс урамы буенча, Гагарин урамы белән кисешкәннән алып Карл Маркс урамындагы 3 нче йортка кадәр.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмат сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А.В. Старостин